**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Екатериновка авылында 2023 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**28 октябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Екатериновка авылы гражданнары җыены,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Екатериновка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 2023 елда 600,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтергә:

1) «Святой ключ» чишмәсен төзекләндерү;

2) Үлән чаптыру, чүп-чар җыю һәм чыгару;

3) Юлны ремонтлау.

3. Әлеге карарны Теләче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Теләче муниципаль районының рәсми сайтына (http:/ tulachi.tatarstan.ru) кую юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче
Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Мараков